## Задания заключительного тура Акмуллинской олимпиады по татарскому языку и литературе для учащихся 8-9 классов

1. Саннар артына яшерелгән мәкальне табыгыз (10 б.).
13, 25, 21, 7, 16, 5, 2, 16 23, 1, 24 7, 21, 1, 13 3, 24, 14, 15, 1, 22.
Чебешләр көз көне санала.

2. Фразеологизмнарның бер сүз белән белдерелгән синонимнарын табыгыз (5 б):
*Кул арасына керә башлау* булышу, ярдәм итү
*Борын салыну* борчылу, кайгыру
*Чыпчык тезеннән* сай
*Табан ялтырату* качу
*Борчаклары пешмәү* уртак тел тапмау, аңлаша алмаганлык.

3. Аваз пропорциясен чишегез (5б.)
Каз : сак = таж : ? чат

4. Табышмакларның җавабын тап (3 б.):
Күлмәкне икегә аерсак, нәрсә була? күл, мәк
Башы “Т”, койрыгы “Н”, дошманы “М”. Ул нәрсә? тычкан
Тугай кайчан сайрый? р өстәсәң, тургай

5. *Кабыну* сүзенең нинди мәгънәләре бар? Мисаллар белән аңлатыгыз (3 б.).
Яну. Өйдә утлар кабынды.
Эшли башлау. Машина кабынды.
Тиз кызучан кеше. Абый кабынып китте.

6. Тексттагы саннарны сүзләр белән языгыз (10 б)
Бүген дөньяда 6809 алты мең сигез йөз тугыз «тере» тел бар, аларның яртысы сигез илгә: Индонезия, Мексика, Бразилия, Камерун, Һиндстан, Кытай, АКШ һәм Рәсәйгә туры килә. Иң күп телле ил – Һиндстан, аның халкы 845 сигез йөз кырык биш диалектта сөйләшә. Аның артыннан Папуа – Яңа Гвинея килә (монда 600 алты йөзләп ләп тел бар).

Планетада иң таралган тел булып кытай, инглиз һәм испан телләре санала. Киң кулланыла торган телләрнең беренче урынлыгына Пекин диалектындагы кытай теле (бу телдә 875 сигез йөз җитмеш биш млн кеше сөйләшә), һинди (366 өч йөз алтмыш алты млн), бенгал (207 ике йөз җиде млн), португал (176 йөз җитмеш алты) млн, рус (167 йөз алтмыш җиде млн), япон (125 йөз егерме биш млн), немец (100 йөз млн) һәм корея (78 җитмеш сигез млн) телләре керә.

Бүген дөньядагы телләрнең туксан процентының (аларны йөз меңнән кимрәк кеше генә белә) киләчәге өметле түгел. ә менә бу телләрнең берничә йөзе, гомумән, үлем чигендә тора: әйтик, 357 өч йөз илле җиде телдә бүген иллешәр кеше генә сөйләшә, ә 46 кырык алты телне, гомумән, берәр кеше генә белә! Галимнәр раславынча, тел яшәсен һәм үссен өчен, бу телдә бер миллионнан артык кеше сөйләшү зарур икән (Матбугаттан).

7. М. Акмулла "Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән" дип язган. Автор турында 5 факт яз (10 б.)

Миякә районы Туксанбай авылында туган,
Мәгърифәтче-шагыйрь; халыкны аң-белемгә өнди
Иң күренекле шигыре „Башкортларым, уку кирәк",
Акмулла исемендәге премия бар,
Укымышлылыгы, туры сүзлелеге өчен халык Акмулла дип атый.

8. Әсәр белән жанрны тәңгәлләштерегез (5 б):

- Ш.Камал "Акчарлаклар" → повесть
- Г.Камал "Беренче театр" → комедия
- М.Фәйзи "Галиябану" → драма
- Г.Әпсәләмов "Ак чәчәкләр" → роман
- Һ.Такташ "Киләчәккә хатлар" → поэма

9. Билгеләнгән алмашлыклар урынына геройның исемен куегыз (5 б.). Әсәрнең авторын күрсәтегез (2 б.) Ф. Әмирхан „Хәят" повесте

....Егетнең йөз кыяфәте һәм сынын тотышы портрет күрсәтүенә караганда, бик сөйкемле иделәр: ачык маңгай, кәкрәебрәк килгән шактый кин кашлар, очлары югарыга каратылып куелган куе вә озын мыек һәм күкрәген киерелдеребрәк, егетсымак торыш АҢА Хәяткә мәхәббәтле күренделәр.

Егетнең кәләпүшеннән башка бөтен киеме иң соң мода белән Европача тегелгән нәрсәләр иде. Портрет иясе бу яктан да АҢА Хәяткә ошады.

УЛ Хәят портретны бик озаклап, бик нечкәләп карады, иң вак нәрсәләрне дә күзеннән төшереп калдырмаска тырышты. Шулай карый торгач, бервакыт аңар егетнең кәләпүше артыграк артка киелгән шикелле тоелды да, ул: «Кәләпүшне бераз алгарак киертәсе бар икән» дип уйлады.

10. Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясендә күтәрелгән проблемалар (6 б.)

Ата-ана алдындагы бурычларны үтәү, телне саклау, туган ягыңны ярату, саклау; олканнарга хөрмәт.

11. Халык сүзе белән әйткәндә, ул «кылны кырыкка яручы» бер бала иде, дип кайсы әдәби геройны сурәтлиләр? (5 б.) Әбугалисинаны.

– Әнкәй! Кара әле, куагыбыз чәчәк аткан бит безнең! – дип, кул чабып кычкырып җибәргән Хәлимә. – Арыкка су җибәрүебез бик яхшы булды, әнкәй. Чәчәкләре элеккегә караганда да матуррак!

– Әйе шул! Яхшы эш, хезмәт беркайчан да әрәм булмый ул, – дигән әнкәсе һәм чәчәкләр арасыннан берсен, иң матурын өзеп алган да кызының чәченә кадап куйган. *(Д.Аппакова)* (398 сүз)

Ялгыз өй янында гөлчәчәк куагы үскән,
Ана белән кыз яңа йортка күчкән,
Гөлчәчәк куагы кышны ялгыз үткәргән,
Язын куак бөреләнмәгән,
Мәрьям апа белән Хәлимә куакка су агызганнар,
Гөлчәчәк куагы чәчәк аткан.

**13. "Яхшы эш, хезмәт беркайчан да әрәм булмый ул, – дигән әнкәсе һәм чәчәкләр арасыннан берсен, иң матурын өзеп алган да кызының чәченә кадап куйган"**, – җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Текстта күтәрелгән проблемага туры китереп, эссе языгыз. Фикерләрегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән 2 мисал китерегез.

Язма эшнең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Эшегезне чиста, төзәтүләрсез һәм таныплык итеп языгыз (25 б.).

Татар халкында „Кешене хезмәт бизи" дигән әйтем бар. Хезмәт кешене бизәп кенә калмый, шатлык та китерә. Хезмәт яраткан кеше - бәхетле кеше. Ул көн дә сөенеп эшенә бара. Бөтен күңелен биреп эшләгәч, хезмәте белән башкаларга файда китерә. Авырлыклар килсә, куркып калмый, тырышлыгы белән яңа уңышлар яулый. Мондый кешеләрне бөтенесе дә хөрмәт итә.

Татар халкы элек-электән хезмәт сөйгән. Балаларны бәләкәйдән үк эшкә өйрәтеп үстергәннәр. Д. Аппакова әсәреннән күренгәнчә, Мәрьям апа кызы Хәлимә белән арыкны тазартып, буасын ачып, су агызып корыган куакны яшәрткәләр, Хәлимә бәләкәйдән үк үз хезмәтенең уңышын татый, яхшы эшнең беркайчан да әрәм булмаганын аңлап үсә.

Мин үзем дә авылда яшим, авыл баласымын. Авылда бәләкәйдән үк хезмәт белән танышабыз. Әнием янында йөрергә, аңа булышырга бик яратам. Язын, көзен әти-әнием белән бакчада эшлибез, төрле яшелчә-җимешләр үстерәбез. Яз җитү белән, бакчада җиң сызганып эшкә тотынабыз: җир казыйбыз, утыртабыз, су сибәбез, утыйбыз. Көзен уңышларны җыябыз. „Җәйге көн ел туйдыра", диләр, кышын үстәлебездән үстергән яшелчә-җимешләр өзелми. Шулай итеп, җир эше белән шөгыльләнәбез, тамагыбыз да тук, үзебездә канәгатьбез. Яхшы хезмәтебез әрәм булмый. Мәктәптә уку да авыр хезмәт. Әйбәт уку да күп сабырлык таләп итә. Без яраткан һөнәр сайлау өчен, белемле кеше булу өчен тырышып укырга телибез.

Минем дәнзем Рәвия Хаматнур кызы да хезмәт юлын

укытучы булып башлап, директорга тиклем күтәрелгән. Ул директор булган чорда мәктәп тагын да алга киткән, компьютер класслары, музей ачылган. Аның мактау кәгазьләре күп. Пенсиягә чыкса да, колхозда Ветераннар Советы председателе нәнәем. Аны бөтен халык хөрмәт итә. Мин аның белән горурланам. „Кешене хезмәт бизи" кебек сүзләр нәкъ нәнәем турында ул. Нинди генә һөнәр иясе булмасын, үз хезмәтен яратып, яхшы итеп башкарган, үзенең эше белән бик күпләрне бәхетле иткән кешеләр хөрмәткә лаек.